ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.08.2024 Олы Кайбыч ав. № 303

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр һәм махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм итү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык

хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр һәм махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән гражданнар махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар балаларының көндезге мәктәп яны лагерьларында ял итү чарасын оештыру.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
Башкарма комитет
Җитәкченең беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина